**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы № **56** **"14"** июнь **2022** ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең **2014** елның **11** ноябрендэге **96** нче номерлы « Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» , шулай ук Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» **2007** елның **2** мартындагы **25-**ФЗ номерлы Федераль закон, **2013** елның **25** июненедәге №**50-**ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Президентының **2009** елның **30** декабрендәге ПУ-**702** номерлы Указы, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында,

Балтач авыл җирлеге Советы карар итте:

**1.**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең **2014** елның **11** ноябрендэге **96** нче номерлы « Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» , шулай ук Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга;

**2.** Әлеге карарны Балтач авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: **http://pravo.tatarstan.ru.** һәм Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: **http//aznakayevo.tatar.ru.**

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис

Л.Л.Хәбипов